| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ БОЛЬШЕТИГАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЗУР ТИГӘНӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** Зур Тигәнәле ав. **КАРАР**

09.06.2023 № 48

**Үз көчен югалткан дип тану турында**

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 121 статьясындагы $4^2$ өлешенә һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 8 өлешенә ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советы

**карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советының 07.04.2016 ел, №36 «Зур Тигәнәле авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәре,мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Зур Тигәнәле авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат тапшыру турында» карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Зур Тигәнәле авыл җирлеге**
**Башлыгы, Совет Рәисе** **М.Ә.Гатин**